**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 16 декабрь № 939

г. Казань

2017 елга «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенең норматив чыгымнарын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2017 елга түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнарын һәм күләмнәрен;

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнарны.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\939.doc

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 декабрь, 939 нчы карары белән расланды

## «Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең норматив чыгымнары һәм күләмнәре

| Т/с | Хезмәтнең исеме | Норматив чыгымнар, бер берәмлеккә 1 елга сум | Бер елга хезмәтләр күләме | Үлчәү берәмлеге |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Архив документлары нигезендә мәгълүмат хезмәтләре күрсәтү | 727,60 | 19 000 | үтәлгән соратулар, берәмлек |
| 2. | Архив документларыннан (күчермәләреннән) һәм аларның белешмә-эзләү чараларыннан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү | 1 017,45 | 6 500 | уку залына керүләр саны, берәмлек |
| | | 1 219,25 | 1 500 | архив үткәрә торган чараларда катнашучылар саны, кеше |
| | | 15,62 | 360 000 | интернет-сайтка керүләр саны, берәмлек |

______________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 декабрь, 939 нчы карары белән расланды

«Татарстан Республикасы Дәүләт архивы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан дәүләт эшләре башкаруга норматив чыгымнар

| Т/с | Эш исеме | Норматив чыгымнар, бер елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Архив документлары белән комплектлау | 9 966 881 |
| 2. | Архив документларының сакланышын тәэмин итү һәм исәпкә алу | 20 218 023 |
| 3. | Архив документларының фәнни тасвирламасы һәм аларның белешмә-эзләү чараларын төзү | 3 490 424 |
| 4. | Документларның библиографик эшкәртмәсе һәм каталоглар төзү | 1 033 184 |
| 5. | Дәүләт серен тәшкил иткән мәгълүматларны, закон нигезендә саклана торган башка серләрне саклау һәм билгеләнгән тәртиптә аларның сер булуын бетерүне оештыру | 3 362 388 |

______________________________

F:\KARAR\2016\939_1.doc